**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге Атабай авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

29 нче ноябрь 2022 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 нче елның 21 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, олешчэ мобилизациядэ булганнар хэм аларнын гаилэ эгьзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пунктта юл-урам челтәрен төзекләндерү һәм зиратка кадәр юл (сатып алу, ташу, таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) җәйге вакытта территорияне чаптыру (КРН-2,1 ротация чапкычының запас өлешләрен сатып алу, ягулык-майлау материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү һәм складлау урынына чыгару, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

5) янгын гидрантларын тоту (янгын краннарын, җайланмаларны әзерләү) кышка - җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына тикшерү һәм әзерләү, ягулык-майлау материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 45 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 29 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 29 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге составына керүче Атабай авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, олешчэ мобилизациядэ булганнар хэм аларнын гаилэ эгьзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пунктта юл-урам челтәрен төзекләндерү һәм зиратка кадәр юл (сатып алу, ташу, таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) җәйге вакытта территорияне чаптыру (КРН-2,1 ротация чапкычының запас өлешләрен сатып алу, ягулык-майлау материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү һәм складлау урынына чыгару, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

5) янгын гидрантларын тоту (янгын краннарын, җайланмаларны әзерләү) кышка - җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына тикшерү һәм әзерләү, ягулык-майлау материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/).

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Сагьдиев